Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил
№___11-0___
Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы
№____1103____
Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы
№_____218______
Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы
№_______116од_________
«Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр
буенча республика агентлыгы
№_____92-п_____

БОЕРЫК

20_22_ ел, __06__ ___20_______

«Ребенок в мире прав» – «Бала хокуклар даирәсендә» мәгълүмати-социаль видеороликларның республика конкурсы турында»гы боерыкка үзгәрешләр кертү хакында

«Ребенок в мире прав» – «Бала хокуклар даирәсендә» мәгълүмати-социаль видеороликларның республика конкурсын үткәрү тәртибен төгәлләштерү һәм Республика конкурсының оештыру комитеты составын актуальләштерү максатларында, **боерабыз:**

«Ребенок в мире прав» – «Бала хокуклар даирәсендә» мәгълүмати-социаль видеороликларның республика конкурсы турында» 2015 елның 2 сентябрендәге Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең № 19, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының № под-9233/15, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының № 533, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының № 01-02/629, «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгының № 30-П уртак боерыкка (2016 елның 13 октябрендәге Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең № 37-о, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының № под-2097/16, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының № 2, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының № 01-02/269, «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгының № 32п боерыклары белән, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 03.09.2018 № 21-о, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 05.09.2018 № под-1307/18, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының 31.08.2018 № 9, Татарстан Республикасы Юстиция

министрлыгының 27.08.2018 № 92 од, «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгының 28.08.2018 №24-п боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Ребенок в мире прав» – «Бала хокуклар даирәсендә» мәгълүмати-социаль видеороликлар республика конкурсының әлеге боерык белән расланган Оештыру комитеты составында:

составтан Г.Л. Удачинаны, Л.О. Сулимны, Е.И. Согринаны, Д.И. Фәттаховны чыгарырга;

составка Ирина Владимировна Волынецны - Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне, Оештыру комитеты рәисен, Асадуллина Алсу Мөниб кызын - Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасарын, Сөләйманов Тимур Җәүдәт улын - Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрын, Петров Максим Вячеславовичны - Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Балалар советы башкарма комитеты рәисен кертергә;

«Ребенок в мире прав» – «Бала хокуклар даирәсендә» мәгълүмати-социаль видеороликлар республика конкурсы турында нигезләмәдә:

3.2 пунктта «Татарстан Республикасы Балалар оешмалары советы» төбәк иҗтимагый оешмасы» сүзләрен «Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Балалар советы» сүзләренә алмаштырырга;

3.4 пунктта «13 кешедән торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.1 пунктта «30 яшькә кадәрге» сүзләрен «35 яшькә кадәрге» сүзләренә алмаштырырга;

5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Конкурста катнашуга дәгъва кылучы агымдагы елның 10 сентябреннән 20 октябренә кадәр әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта нигезендә билгеләнгән https://forms.yandex.ru/u/627803a5723c9911682a00a2/ сылтамасы буенча электрон формада (Яндекс-форма) теркәлү уза, анда социаль челтәрдә басылып чыккан видеороликка сылтаманы күрсәтә ала (теләге булса). Теләсә нинди форматта (Word, PDF һ.б.) тутырылган теркәлү бите түбәндәге электрон адреска җибәрелә: rebenok-v-mire-prav@yandex.ru.».

Теркәлү битенә түбәндәгеләр өстәлеп җибәрелә:

видеоролик;

әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтадагы форма буенча шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык;

әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымтадагы форма буенча тарату өчен шәхси белешмәләр субъекты тарафыннан рөхсәт ителгән шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык.

Түбәндәгеләр карауга алынмый:

әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән срок узганнан соң җибәрелгән видеороликлар;

теркәлү битләреннән башка җибәрелгән видеороликлар;

Конкурс тематикасына туры килми торган видеороликлар.»;

5.5 пунктның өченче абзацында «катнашу өчен гаризалар» сүзләрен «теркәлү битләре» сүзләренә алмаштырырга, «гаризалар» сүзен «теркәлү битләре» сүзләренә алмаштырырга, «гаризада» сүзен «теркәлү битендә» сүзләренә алмаштырырга;

5.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.12. Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Балалар советы, агымдагы елның 15 ноябреннән дә соңга калмыйча, Совет әгъзаларының тавыш бирүе юлы белән, әлеге Нигезләмәнең 5.4 пункты нигезендә социаль челтәрләрдә урнаштырылган иң яхшы видеороликны билгели. Җиңүче күпчелек тавыш белән билгеләнә;

«Ребенок в мире прав» – «Бала хокуклар даирәсендә» республика мәгълүмати-социаль видеороликлар конкурсы турында нигезләмәгә кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ребенок в мире прав» – «Бала хокуклар даирәсендә» мәгълүмати-социаль видеороликларның республика конкурсы турында нигезләмәгә
1 нче кушымта»

**«Ребенок в мире прав» – «Бала хокуклар даирәсендә» мәгълүмати-социаль видеороликларның республика конкурсында катнашу өчен теркәлү бите**

**<u>I. Төркем яки иҗат коллективы өчен:</u>**

1.1. Төркемнең (булса) / иҗат коллективының исеме

1.2. Төркем / иҗат коллективы җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса)

1.3. Төркемнең / иҗат коллективының һәр катнашучысының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса), туган көне

1.4. Үзендә төркем / иҗат коллективы төзегән белем бирү оешмасының исеме

1.5. Үзендә төркем / иҗат коллективы төзегән белем бирү оешмасының элемтә белешмәләре (телефон номеры, почта адресы, электрон почта адресы)

1.6. Төркем / иҗат коллективы җитәкчесенең элемтә белешмәләре (телефон номеры, почта адресы, электрон почта адресы)

1.7. Муниципаль берәмлек исеме

1.8. Видеороликның исеме һәм жанры

1.9. Видеороликны социаль челтәрләрдә урнаштыру турында мәгълүмат (теләк буенча)

**<u>II. Шәхси катнашучылар өчен:</u>**

2.1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса)

2.2. Туган көне

2.3. Катнашучы белем ала торган мәгариф оешмасының һәм сыйныфның исеме

2.4. Катнашучының ата-анасының / башка законлы вәкилнең элемтә белешмәләре (телефон номеры, почта адресы, электрон почта адресы)

2.5. Муниципаль берәмлек исеме

2.6. Видеороликның исеме һәм жанры

2.7. Социаль челтәрләрдә видеороликны урнаштыру турында мәгълүмат (теләк буенча)»;

«Ребенок в мире прав» – «Бала хокуклар даирәсендә» мәгълүмати-социаль видеороликларның республика конкурсы турындагы нигезләмәгә түбәндәге редакциядә 2 нче кушымта өстәргә:

«Ребенок в мире прав» – «Бала хокуклар даирәсендә» мәгълүмати-социаль видеороликларның республика конкурсы турында нигезләмәгә
2 нче кушымта»

**Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык***

Мин,______________________________________________________________
__________________________________________________________________________,

катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булса)

элемтә өчен телефон: __________, электрон почта адресы ____________________,

«Шәхси белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә үз ихтыярым белән һәм үз мәнфәгатьләремдә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә (К. Маркс ур., 61, Казан шәһәре, 420016) (алга таба - Оператор) «Ребенок в мире прав» – «Бала хокуклар даирәсендә» мәгълүмати-социаль видеороликларның республика конкурсын (алга таба - Конкурс) уздыру кысаларында Конкурста катнашучылар белешмәләре базасын булдыру максатында үземнең шәхси белешмәләрне, автоматлаштырылган чаралар кулланып, шулай ук андый чаралар кулланмыйча да, эшкәртүгә, Конкурста җиңүчеләрнең казанышлары турында һәм Конкурста җиңүчеләр турында мәгълүмат урнаштыруга ризалык бирәм.

Шушы Ризалык белән Операторга түбәндәге шәхси белешмәләр категорияләренә керүче үземнең шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалыгымны бирәм:

1. Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булса)
2. Телефон номеры
3. Белем бирү оешмасы

Мин шәхси белешмәләрне бары тик түбәндәге максатларда гына кулланырга ризалык бирәм:

Конкурста катнашу өчен гаризалар әзерләү һәм эшкәртү;

Конкурска тәкъдим ителгән эшне карау;

Конкурс нәтиҗәләрен урнаштыру;

югарыда күрсәтелгән максатларга бәйле башка гамәлләр.

Матбугат басмаларында урнаштырыла торган мәгълүмати һәм башка материаллардагы үз рәсемнәремне Конкурс турында мәгълүмат бастырып чыгару кысаларында интернет челтәрендә, радио- һәм телевизион эфирда кулланырга ризалык бирәм.

Рәсемнәр минем намусыма, абруема һәм эшлекле репутациямә тап төшерә торган ысуллар белән файдаланыла алмый.

Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә әлеге ризалык бирелгән вакыттан чикләнмәгән срокта гамәлдә була һәм, Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә Операторга гади язма рәвештә гариза бирелгәндә, минем тарафтан кире алынырга мөмкин.

20___ ел, ___ ____________ __________________ _________________

(Конкурста катнашучы имзасы) (фамилиясе, инициаллары)

* Балигъ булмаган катнашучылар исеменнән ризалыкны аларның ата-аналары / законлы вәкилләре бирә»;

«Ребенок в мире прав» – «Бала хокуклар даирәсендә» мәгълүмати-социаль видеороликларның республика конкурсы турындагы нигезләмәгә түбәндәге редакциядә 3 нче кушымта өстәргә:

«Ребенок в мире прав» – «Бала хокуклар даирәсендә» мәгълүмати-социаль видеороликларның республика конкурсы турында нигезләмәгә
3 нче кушымта»

**Тарату өчен шәхси белешмәләр субъекты тарафыннан рөхсәт ителгән шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык***

Мин,________________________________________________________________
__________________________________________________________________________,

катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булса)

элемтә өчен телефон: ____________, электрон почта адресы __________________,

«Шәхси белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 10[1] статьясына таянып, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә (К. Маркс ур., 61, Казан шәһәре, 420016), ИНН 165 812 9870, ОГРН 1111690075331) (алга таба - Оператор) «Ребенок в мире прав» – «Бала хокуклар даирәсендә» мәгълүмати-социаль видеороликларның республика конкурсын (алга таба - Конкурс) уздыру кысаларында минем шәхси белешмәләрне оештыручыларның рәсми сайтларында минем турында мәгълүмат урнаштыру максатында түбәндәге тәртиптә таратуга ризалыгымны бирәм:

| Шәхси белешмәләр категориясе | Шәхси белешмәләр исемлеге | Таратуга рөхсәт бирәм (әйе/юк) | Чикләнмәгән затлар даирәсенә таратуга рөхсәт бирәм (әйе/юк) | Рөхсәт итмәү шарт-лары | Өстәмә шартлар |
|---|---|---|---|---|---|
| Гомуми шәхси белешмәләр | Фамилия | | | | |
| | Исем | | | | |
| | Ата исеме (булса) | | | | |
| | Белем бирү оешмасы | | | | |
| | Социаль статус | | | | |
| Биометрик шәхси белешмәләр | Йөзнең төсле цифрлы фотосурәте | | | | |

Чикләнмәгән затлар даирәсенә керүче һәм шәхси белешмәләр субъектының шәхси белешмәләре белән бүтән гамәлләр башкаручы Операторның мәгълүмат ресурслары турында белешмәләр:

| Мәгълүмат ресурсы | Шәхси белешмәләр белән гамәлләр |
|---|---|
| | Чикләнмәгән затлар даирәсенә керү |

Әлеге ризалык минем тарафтан ихтыярый рәвештә бирелде һәм ул 20___ елның ____ ________________ 20___ елның ___ __________________ кадәр гамәлдә була.

Үзем турында шәхси белешмәләр таратуны туктатырга таләп итү хокукын калдырам. Шундый таләп булган очракта, Оператор минем шәхси белешмәләрне

таратуны кичекмәстән туктатырга, шулай ук минем шәхси белешмәләр тапшырылган өченче затлар исемлеге турында хәбәр итәргә тиеш.

| _________ | _____________ | ________________________________ |
|---|---|---|
| дата | имза | фамилия, инициаллар |

*Балигъ булмаган катнашучылар исеменнән ризалыкны аларның ата-аналары/башка законлы вәкилләре бирә»;

Татарстан Республикасында
Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил — И.В. Волынец

Татарстан Республикасы
мәгариф һәм фән министры — И.Г. Һадиуллин

Татарстан Республикасы
яшьләр эшләре министры — Т.Җ. Сөләйманов

Татарстан Республикасы
юстиции министры — Р.И. Заһидуллин

«Татмедиа» матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр буенча республика
агентлыгы җитәкчесе — А.С. Сәлимгәрәев